КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 декабрь г.Казань № 1562

2024 - 2026 елларга балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләрне алучыларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Тормышта авыр хәлдә калган һәм социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнарга социаль хезмәтләр күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 - 2026 елларга балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 11 ноябрь, 1203 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 5 сентябрь, 1080 нче карары белән расланды

2024 - 2026 елларга балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар

I. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле норматив чыгымнар

| Т/с | Оешма төре, социаль хезмәт күрсәтү төре | Норматив чыгымнар, сум/койка көне | |
|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасы | |
| | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 1. | Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре | 2 163,43 | - |
| 1.1 | социаль һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү | 537,04 | - |
| 1.2. | социаль һәм медицина хезмәтләре күрсәтү | 251,47 | - |
| 1.3. | социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү | 70,11 | - |
| 1.4. | социаль-педагогик хезмәтләр күрсәтү | 1 052,78 | - |
| 1.5. | социаль һәм эш хезмәтләре күрсәтү | 112,56 | - |
| 1.6. | социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтү | 139,47 | - |

II. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнар

| Т/с | Оешма төре | Норматив чыгымнар, сум/койка көне | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|
| | | | хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәте өчен түләү фондына | башка чыгымнарга |
| 1. | Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре | 183,03 | 130,75 | 52,28 |

______________________________